ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.11.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4286**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 29 декабрендәге «2024 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру» 3794 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 07 сентябрендәге «2024-2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 1099 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 29 декабрендәге «2024 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне» 3794 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, РФ Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальонында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция

барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы, РФ Федераль иминлек хезмәтенең ТР буенча идарәсе хезмәткәрләре гаиләләреннән булган, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) яки инвалид булган гаиләләре (гаилә әгъзалары) балаларына һәр уку көненә 105 сум 44 тиен күләмендә билгеләргә».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы - җитәкче урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин